**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

Азнакай шәһәре № 297-40 2019 елның 6 декабре

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 нче статьясы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карар нигезләмәләре Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетын төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә, 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеттан башлап барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http: //pravo. tatarstan. ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http: //aznakayevo. tatarstan. ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай район
Советы карарына кушымта
«06» декабрь, 2019 ел, № 297-40

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетларына шәһәр һәм авыл җирлекләре гражданлык хәле актларын теркәү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен бюджеттан субвенцияләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр) тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлек бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында»2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлү Татарстан Республикасы Азнакай район Советының тиешле

финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Граждан хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылу өлешендә субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

хезмәткә түләү һәм хезмәт өчен түләү хисаплау;

командировка чыгымнары;

элемтә хезмәтләре;

транспорт хезмәтләре;

коммуналь хезмәтләр;

мөлкәтне файдалану буенча хезмәтләр;

мөлкәтне карап тоту буенча эшләр, хезмәтләр;

башка эшләр, хезмәтләр;

төп чаралар сатып алу;

матди запаслар сатып алу;

салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү;

башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – казначылык) шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләрнең бюджетлары чыгымнары турындагы хисапны

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләрнең Башкарма комитетына тапшыралар.

12. Башкарма комитетка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына билгеләнмәгән субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотуны Башкарма комитет һәм «Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы»муниципаль казна учреждениесе закон нигезендә башкаралар.